ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 өлешенә (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш ); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле 18 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«18) Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән, муниципаль район территориясендә урнашкан индустриаль парк (сәнәгать паркы) территориясендәге инфраструктура объектларыннан файдалана торган һәм индустриаль парк (сәнәгать паркы) территориясендә эшчәнлек алып бару турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы белән килешү төзегән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары.

Салым ташламасы индустриаль парк (сәнәгать паркы) территориясендә эшчәнлек алып бару турында килешү төзелгән датага индустриаль парк (сәнәгать паркы) мәйданының иң күбе 70 проценты биләнгән булу шарты үтәлгәндә бирелә һәм индустриаль парк (сәнәгать паркы) территориясендә эшчәнлек алып бару турында килешү төзелгән айдан соң килә торган айның 1 числосыннан башлап мондый килешүнең гамәлдә булу срогына, әмма иң күбе 10 елга кулланыла.

Индустриаль парк (сәнәгать паркы) территориясендә эшчәнлек алып бару турында килешүне төзү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 28 апрель
№ 25-ТРЗ